# <u>“Мин бит татар малае” республика конкурсында</u>

**“ Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге” елы юңаеннан Алабуга шәһәре республиканың бакча балалары арасында “Татар малае” конкурсы оештырды. Беренче тур заочный булды, без бу турдан уңышлы үтеп финалга чыктык. Конкурсның финал өлеше Алабуга шәһәрендә үтте. Безнең Шәйхетдинов Ислам бик матур чыгыш ясап “Иң сөйкемле татар малае” исемен яулады.**












